**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3289**
**28.06.2019**

Башкарма комитетның «Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын кире алу турында» 2019 елның 11 июнендәге 2976 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын кире алу турында» 2019 елның 11 июнендәге 2976 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның 2 пунктчасында «Эссен Продакшн АГ» ЯАҖ» сүзләрен «Эссен Продакшн АГ» АҖ» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 пунктның 1 пунктчасын «Челнинские известия» сүзләреннән соң «Шәһри Чаллы» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 2 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә, законда билгеләнгән тәртиптә, әлеге карарның күчермәсен әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир участокларына хокукы булган затларга җибәрергә».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Р.Ә. Абдуллин